ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерже шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июль 2019 ел. № 293

2019 елга гомуми белем бирү оешмаларында
балаларны йөртү өчен
махсус билгеләнгән автобуслар белән
укучыларны ташуны оештыру буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүдә
бәя нормативларын раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июленнән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Мәктәпләрдә пассажирлар йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары турында" 2010 елныц 6 декабреннән 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтадагы 2019 елга гомуми белем бирү оешмаларында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларны ташуны оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормативларын расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмалары укучыларын әлеге карарның 1 пункты белән расланган Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларына ярашлы рәвештә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елга гомуми белем бирү оешмаларында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән укучыларны ташуны оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормативларын раслау турында»2018 елның 10 октябреннән 447 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкченең беренче урынбасары** **Р.Р.Гильмутдинова**

Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 22 июле, № 293
номерлы карары белән расланган

2019 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасы өчен ставка, елга сум | автотранспорт чарасы побегының бер километрына ставка, сум |
| КАВЗ | 114254 | 36,60 |
| ПАЗ | 114511 | 36,54 |
| ГАЗ «Газель» | 108623 | 29,95 |
| УАЗ | 108170 | 28,64 |
| FIAT | 107912 | 27,25 |
| Peugeot Boxer | 108427 | 26,89 |
| Ford Transit | 109251 | 29,98 |
| КамАЗ Марко-Поло | 112179 | 33,41 |